МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУР Ы РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.08.2014 г. Казань №880од

Россия Федерациясе төбәкләренең 2014 елда этномәдәни проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы иҗтимагый оешмаларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы грантларын алуга конкурс турында нигезләмәне раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 15 гыйнварындагы 28-р номерлы Боерыгын үтәү йөзеннән,

БОЕРАМ:

1 Россия Федерациясе төбәкләренең 2014 елда этномәдәни проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы иҗтимагый оешмаларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы грантларын алуга конкурс турында нигезләмәне расларга.

2. Россия Федерациясе төбәкләренең 2014 елда этномәдәни проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы иҗтимагый оешмаларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы грантларын алучыларны билгеләү советы составын расларга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Министр** **А.М.Сибагатуллин**

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгының
04.08.2014 елның 880 од
____ номерлы боерыгына
1 нче кушымта

**Россия Федерациясе төбәкләренең 2014 елда этномәдәни проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы иҗтимагый оешмаларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы грантларын алуга конкурс турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1 Әлеге Нигезләмәдә 2014 елда милли үзенчәлекләрне саклап калу, телне, мәгарифне, милли мәдәниятне үстерү максатларында Россия Федерациясе төбәкләренең 2014 елда этномәдәни проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы иҗтимагый оешмаларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы грантларын (алга таба – грант-субсидия) алуга конкурс уздыруның тәртибе билгеләнә.

1.2. Грант-субсидия конкурс нигезендә бер тапкыр түләнә.

1.3. Грант-субсидия алуга конкурс Россия Федерациясе төбәкләрендәге оешмалар арасында түбәндәге номинацияләрдә уздырыла:

Россия Федерациясе төбәкләрендә татар халкының гореф-гадәтләрен һәм йолаларын саклап калуга, милли мәдәниятен үстерүгә юнәлтелгән этномәдәни проектлар;

Балалар һәм яшьләр арасында яшьләрдә татар халкының милли тәңгәллеген формалаштыруга юнәлтелгән эш алып бару буенча проектлар;

Татарларның этномәдәни потенциалын үстерү буенча мәгълүмати-аналитик проектлар, татар этносын саклап калу һәм үстерү мәсьәләләре буенча фәнни һәм фәнни-гамәли конференцияләр уздыру.

1.4. Грант-субсидияләрнең гомуми фонды 5,0 млн. сум тәшкил итә, шулардан:

Россия Федерациясе төбәкләрендә татар халкының гореф-гадәтләрен һәм йолаларын саклап калуга, милли мәдәниятен үстерүгә юнәлтелгән этномәдәни проектлар номинациясе буенча грант-субсидия фонды 2 500 000 (ике миллион биш йөз мең) сум тәшкил итә;

Балалар һәм яшьләр арасында яшьләрдә татар халкының милли тәңгәллеген формалаштыруга юнәлтелгән эш алып бару буенча проектлар номинациясе буенча грант-субсидия фонды 1 500 000 (бер миллион биш йөз мең) сум тәшкил итә;

Татарларның этномәдәни потенциалын үстерү буенча мәгълүмати-аналитик проектлар, татар этносын саклап калу һәм үстерү мәсьәләләре буенча фәнни һәм фәнни-гамәли конференцияләр уздыру номинациясе буенча грант-субсидия фонды 1 000 000 (бер миллион) сум тәшкил итә.

## II. Конкурста катнашу хокукы һәм документлар кабул итү тәртибе

2.1. Конкурста Россия Федерациясе төбәкләренең законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән, үз эшчәнлекләрен конкурсның сайлап алу туры игълан ителгәнгә кадәр 1 ел дәвамында гамәлгә ашырган, уставларында татар халкының мәдәни мирасын, телен, тарихын пропагандалау буенча социаль, мәгълүмати, мәдәни, мәгърифәти, фәнни функцияләрне гамәлгә ашыру төп максатлары буларак күрсәтелгән иҗтимагый оешмалар катнаша ала.

2.2. Иҗтимагый оешмаларның проектны гамәлгә ашыру чыгымнарының гомуми суммасыннан 20 проценттан да кимрәк булмаган күләмдә аны бюджеттан тыш чыганаклар хисабыннан финансларга йөкләмә алулары грант-субсидияләр бирүнең төп шарты булып тора.

2.3. Грант-субсидияләр бирү Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының иҗтимагый оешмалар белән төзегән килешүе (алга таба – килешү) нигезендә гамәлгә ашырыла, анда түбәндәгеләр карала:

а) проектны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнар төрләре, аның финанслар белән тәэмин ителүе;

б) субсидия күләме;

в) килешүдә билгеләнгән күрсәткечләр нигезендә субсидияне файдалануның нәтиҗәлелеге;

г) коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан файдаланылган суммаларның, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм башка вәкаләтле органнар тарафыннан уздырылган тикшерүләр йомгаклары буенча ачыкланган очракта, кайтарылу тәртибе;

д) субсидияне файдалану турындагы хисаплар бирү тәртибе һәм сроклары;

е) иҗтимагый оешманың Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия алучыларның аны алуның килешүдә билгеләнгән шартларын, максатларын һәм тәртибен бозмавын тикшерүенә ризалыгы.

2.4. Иҗтимагый оешмаларны сайлап алу Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы билгеләгән тәртиптә һәм түбәндәге критерийлар нигезендә башкарыла:

а) тәкъдим ителгән эшләрнең Конкурсның игълан ителгән номинацияләренә һәм шартларына җавап бирүе;

б) матди-техник һәм кадрлар ресурслары булу;

в) иҗтимагый оешма тәкъдим итә торган проектларның иҗади үзенчәлеге, сәнгати яктан кыйммәте һәм актуальлеге.

2.5. Россия Федерациясе төбәкләренең иҗтимагый оешмалары конкурска бары бер генә проект тәкъдим итәргә хокуклы.

2.6. Грант-субсидия алырга теләүче грант-субсидия алуга конкурста катнашу өчен 2014 елның 1 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына түбәндәге документларны бирә:

а) Россия Федерациясе төбәкләренең 2014 елда этномәдәни проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы иҗтимагый оешмаларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы грантларын алуга конкурс турындагы нигезләмәнең (алга таба – Нигезләмә) 1 нче кушымтасында бирелгән форма буенча заявка;

б) дәүләт теркәвенә алыну турындагы таныклык;

в) уставның оешма мөһере һәм җитәкче имзасы белән расланган копиясе;

г) Конкурста катнашуга заявкалар алына башлаганга кадәр өч ай кала Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан бирелгән күчермә копиясе;

д) әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча проектның тасвирламасы;

е) уртак финанслау гарантияләнгән хат;

ж) бирелүче документларның исемлеге.

Россия Федерациясе төбәкләре иҗтимагый оешмалары тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 2.6 пунктының «б», «в» һәм «г» пунктчаларында күрсәтелгән документлар бирелмәгән очракта, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы әлеге документларны дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнарыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә сората.

2.7. Әлеге Нигезләмәнең 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итү һәм теркәү Грант-субсидияләр алучыларны билгеләү Советының җаваплы секретаре тарафыннан башкарыла. Заявкалар 2014 елның 1 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына түбәндәге адреска тапшырыла: 420015, Казан шәһәре, Пушкин урамы, 66/33, 420 нче кабинет. Телефон: (843) 264-73-96.

2.8. Конкурста катнашу турындагы заявканың кире кагылуына нигез булып заявкаларны тапшыру вакытын бозу тора.

Әгәр заявкага әлеге Нигезләмәнең 2.6 пунктының «д», «е», «ж» пунктчаларында күрсәтелгән документлар теркәлмәгән булса, Россия Федерациясе төбәкләре иҗтимагый оешмалары әлеге Нигезләмәнең 2.7 пунктында билгеләнгән вакыт узганчы җитешмәгән документларны тапшыру хокукына ия.

2.9. Конкурсны уздыру тәртибе, вакыты, анда катнашу өчен сайлап алу шартлары һәм критерийлары Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының рәсми сайтында (http://mincult.tatarstan.ru, Грантлар, Премияләр бүлегендә) документлар кабул ителү вакыты чыкканчы 15 көн кала урнаштырыла.

## III. Советны формалаштыру тәртибе

3.1. 13 кешедән торучы Грант-субсидияләр алучыларны билгеләү Советы (алга таба - Совет) Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы боерыгы белән раслана. Совет Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы вәкилләреннән, мәдәният өлкәсе белгечләреннән, җәмәгатьчелек вәкилләреннән формалаштырыла һәм аның составына рәис, рәиснең ике урынбасары һәм совет әгъзалары керә.

Советка конкурсның сайлап алу туры нәтиҗәләрендә шәхси кызыксынган затлар (заявкалар биргән оешмалар штатында торучылар) яисә конкурсның

сайлап алу турында катнашучылар йогынты ясарга сәләтле затлар билгеләнергә тиеш түгел.

3.2. Совет эшчәнлеге аның утырышларында гамәлгә ашырыла. Совет, әгъзаларының гомуми санынннан күпчелеге утырышта катнашса, гамәл йөртергә хокуклы була.

3.3. Совет эшчәнлегенә рәис җитәкчелек итә. Совет рәисе эш урынында булмаганда, аның вазыйфалары ул үзе күрсәткән рәис урынбасарына йөкләнә.

Совет карарлары ачык тавыш бирү юлы белән, утырышта катнашкан совет әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3.4. Советның оештыру-техник эшчәнлеген координацияләү, утырышларын әзерләү һәм документлар тутыру өчен Совет рәисе Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы хезмәткәрләре арасыннан Советның җаваплы секретарен билгеләп куя.

3.5. Советның җаваплы секретаре түбәндәге функцияләрне үти:

Совет утырышларында карау өчен материаллар әзерли һәм аларның саклануын оештыра;

Советның барлык әгъзалары, грант-субсидиягә заявка бирүчеләр белән элемтәдә тора;

Совет утырышларын оештыра;

Совет утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә.

3.6. Советның җаваплы секретаре Совет составына керми һәм аның утырышларында тавыш бирү хокукыннан башка гына катнаша.

## IV. Конкурсны уздыру һәм грант-субсидияләр бирү тәртибе

4.1. Әлеге Нигезләмәнең 2.6 пунктында күрсәтелгән заявкалар һәм документлар бирү срогы чыккан вакыттан 10 календарь көн дәвамында Совет утырышы уздырыла, анда теркәлгән документлары белән алынган заявкалар карала, грант-субсидия алуга конкурста катнашучы затлар билгеләнә. Совет утырышының Конкурста катнашучыларны билгеләү турындагы беркетмәсе Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы сайтында өч эш көне дәвамында урнаштырыла.

4.2. Конкурста катнашуга уздырылмаган заявка тапшыручыларга мәгълүмат бирү Совет секретаре тарафыннан Советның Конкурста катнашучыларны билгеләү буенча беркетмәсен рәсмиләштерү вакытыннан өч эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

4.3.Конкурс уздыру өчен Совет әгъзалары бирелгән проектларны 2014 елның 11 сентябреннән 19 сентябренә кадәр 10 баллы шкала (0 дән 10 га кадәр) буенча бәяли:

бүлеп бирелә торган грант-субсидия кысаларында социаль әһәмиятле проблеманы хәл итү буенча чараларның проект буларак эшләнү дәрәҗәсе (проектның гамәлгә ашырылу мөмкинлеге, аның конкрет һәм әһәмиятле нәтиҗәгә юнәлдерелгәнлеге, проектны гамәлгә ашыру этапларының эзлеклелеге, грант-субсидия кысаларында финанслау төгәлләнгәннән соң үз ресурслары нигезендә әлеге эшчәнлекне дәвам итү мөмкинлекләре) (0 дән 10 га кадәр);

социаль әһәмияткә ия булган проектны гамәлгә ашыру өчен заявкада күрсәтелгән күләмдә акча сорауның нигезле булуы (0 дән 10 га кадәр);

ахыргы нәтиҗәнең актуальлеге, аны гамәлдә файдаланунын актуальлеге, Россия Федерациясе төбәгенең социаль үсеше өчен проектның югары социаль һәм иҗтимагый әһәмияткә ия булуы (0 дән 10 га кадәр);

социаль әһәмияткә ия булган проектның икътисадый яктан максатка ярашлыгы һәм аның нәтиҗәлелеге (чыгымнарның һәм планлаштырылган нәтиҗәләрнең чагышмасы) (0 дән 10 га кадәр);

өстәмә рәвештә акча куллану (шул исәптән проектларны финанслауда өченче затларның катнашуы) (0 дән 10 га кадәр).

Татарларның этномәдәни потенциалын үстерү буенча мәгълүмати-аналитик проектлар, татар этносын саклап калу һәм үстерү мәсьәләләре буенча фәнни һәм фәнни-гамәли конференцияләр уздыру номинациясе буенча заявка бирүчеләр планлаштырылган матбугат басмалары өчен ике рецензия һәм экспертлар бәяләмәсе тапшыра. Рецензияләрнең берсе һәм эксперт бәяләмәсе Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт фәнни-мәгариф учреждениеләре галимнәре тарафыннан бирелә.

4.4. Һәр критерий буенча баллар суммасына нигезләнеп Совет Конкурста катнашучылар рейтингын төзи. Һәр номинациядә рейтингта беренче егерме урынны алган катнашучылар проектлары Совет каравына җибәрелә.

4.5. Конкурста катнашучылар рейтингы Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы сайтында өч эш көне дәвамында урнаштырыла.

4.6. Грантлар күләме соралган суммага, рейтингта биләгән урынга һәм әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктында билгеләнгән средстволар чагышмасы үтәлүен исәпкә алып бүленә.

4.7. Конкурс йомгаклары Совет тарафыннан 2014 елның 29 сентябренә кадәр ясала һәм беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә. Беркетмә нигезендә өч эш көне дәвамында Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Конкурста җиңүчеләр турында боерыгы чыгарыла.

4.8. Конкурска тәкъдим ителгән эшләр катнашучының (заявительнең) шәхси гаризасы нигезендә 2015 елның 31 декабренә кадәр кайтарыла.

4.9. Конкурста җиңүчеләр турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге сайтында Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы боерыгы чыккан көннән соң биш көн эчендә урнаштырыла.

## V. Грант-субсидия алучыларга акча түләү тәртибе

5.1. Грант-субсидияләр түләү өчен акча күчерү Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм грант-субсидияләр алучылар арасындагы килешүләр нигезендә грант-субсидияләр алучылар счетларына субсидияләр рәвешендә (әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымта) яклар тарафыннан килешүләр төзелгәннән соң 14 көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

5.2. Һәр номинация буенча грант-субсидияләр түләүдән калган акча Татарстан Республикасы бюджетына керем буларак Совет тарафыннан һәр номинация буенча грант-субсидияләр бирү турындагы карар кабул ителгән көннән 17 көн дәвамында кайтарылырга тиеш.

## VI. Грант-субсидияләр алучыларның хисап бирү тәртибе һәм сроклары

6.1. Грант-субсидияләр алучылар 2014 елның 19 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына грант-субсидияләр түләүгә бүлеп бирелгән акчаның тиешле максатта файдаланылуы һәм иҗади эшчәнлек нәтиҗәләре турында фото(видео) материаллар теркәлгән хисаплар бирәләр.

6.2. Иҗади эшчәнлек нәтиҗәләре турындагы хисапта түбәндәге позицияләр күрсәтелә:

иҗади проектларның социаль әһәмияткә ия булуы;

катнашучылар саны;

җәмәгатьчелек фикеренә (массакүләм мәгълүмат чараларындагы хәбәрләргә) күзәтү.

6.3. Татарларның этномәдәни потенциалын үстерү буенча мәгълүмати-аналитик проектлар, татар этносын саклап калу һәм үстерү мәсьәләләре буенча фәнни һәм фәнни-гамәли конференцияләр уздыру номинациясе буенча басма продукциядә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

ISBN;

копирайт;

басманың чыгарылу белешмәләре турында тулы мәгълүмат;

проект финансланган чыганакны мәҗбүри күрсәтү («Проект Россия Федерациясе төбәкләренең 2014 елда этномәдәни проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы иҗтимагый оешмалары өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының грант-субсидия акчасына башкарылды»).

6.4. Грант-субсидияләр средстволарны файдалану турындагы хисап бирелгәннән соң 60 көн дәвамында Татарстан Республикасы бюджетына керем буларак түбәндәге очракларда кайтарылырга тиеш:

грант-субсидияләр алучылар тарафыннан дөреслеккә туры килмәгән мәгълүмат бирелү;

грант-субсидияләр бирү шартларын үтәмәү;

грант-субсидияләрне тиешле максатта файдаланмау.

Татарстан Республикасы бюджетына әлеге акчаны ирекле кайтарудан баш тартканда, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүриләп кайтарылырга тиеш.

6.5. Грант – субсидияләрне тиешле максатларда файдалануны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы контрольдә тота.

Россия Федерациясе төбәкләренең 2014 елда этномәдәни проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы иҗтимагый оешмаларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы грантларын алуга конкурс турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

**Россия Федерациясе төбәкләренең 2014 елда этномәдәни проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы иҗтимагый оешмаларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы грантларын алуга конкурста катнашуга**
**заявка**

1. Заявка бирүче оешманың атамасы, ИНН:
______________________________________________________________________________
2. Адресы: _________ __________________________________________________________
(индекс) (юридик адресы)
_______ _________________ E-mail: ______________________________________
(телефон) (факс)
3. Оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме:
_____________________________________________________________________________
тел.:___________________
Адресы: ________________________________________ E-mail: ___________________
4. Заявка бирүче оешма эшчәнлеге төрләре турында мәгълүмат:

_______________________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________________

5. Проектның исеме: ____________________________________________________
Проектның юнәлеше: ______________________________________________________
Проектның авторы: ______________________________________________________________
Элемтә өчен мәгълүмат:
_____________________________________________________________________________
6. Сезнең дәүләт гранты яисә муниципаль грант алганыгыз бармы? Әгәр булса, елын һәм исемен, грантның атамасын һәм суммасын күрсәтегез:

_______________________________________________________________________________________

7. Проектка кыскача аннотация (бу бүлектә 100 сүздән дә арттырмыйча проектның төп кисәкләренең кыскача эчтәлеге бирелә, проектның кирәклеге дәлилләнә):

_______________________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________
___
8. Түләү реквизитлары
Банкның атамасы: ____________________________________________________
адресы:
_____________________________________________________________________________
р/с: _________________________________________________________________

Заявкада, проект тасвирламасында күрсәтелгән барлык мәгълүмат, шулай ук өстәмә материаллар дөрес һәм ышанычлы булуы турында белдерәм, һәм вәкаләтле органның бирелгән белешмәләргә төгәллек кертү өчен бездән һәм дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарында мәгълүмат соратырга хокукын раслыйм.

Җитәкченең Ф.И.А ис. ____________________________________ /_____________/
(имза)

М.У.

«Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль Закон нигезендә минем персональ мәгълүматларымны эшкәртүгә каршы килмим.

Җитәкченең Ф.И.А ис ____________________________________ /_____________/
(имза)

М.У.
Дата:

Россия Федерациясе төбәкләренең 2014 елда этномәдәни проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы иҗтимагый оешмаларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы грантларын алуга конкурс турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

**Россия Федерациясе төбәкләренең 2014 елда этномәдәни проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы иҗтимагый оешмаларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы грантларын алуга конкурста катнашу проекты тасвирламасы**

(5 биттән дә артык түгел)

1. Проект гамәлгә ашырыла башлаган вакыттагы вәзгыятькә гомуми характеристика (1 биттән дә артык түгел):

| |
|---|
| |

2. Проектның максатлары һәм бурычлары:

| |
|---|
| |

3. Төп чараларның тасвирламасы, проектны гамәлгә ашыруның этаплары һәм сроклары:

| т/с | Гамәлгә ашыру этабы | Чараларның атамасы | Гамәлгә ашыру сроклары |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |

4. Проектны гамәлгә ашыруга идарә итү механизмы:

| |
|---|
| |

5. Чама белән исәпләнгән керемнәр һәм планлаштырылучы чыгымнар сметасы, аны нигезләү:

Чыгымнарның гомуми күләме (сумнарда):

Соратылучы субсидия күләме (сумнарда):

Уртак финанслаunion чама белән исәпләнгән керемнәр (сумнарда):

(сумнарда)

| т/с | Чыгымнарның атамасы | Үз акчалары | Соратылучы акчалар | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| Барлыгы: | | | | |

Шәрехләү:____________________________________________________________

6. Проектны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре:

| № п/п | Нәтиҗәлелек күрсәткече | Күрсәткечнең саннарда чагылышы |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

7. Партнерлар турында мәгълүмат:

| |
|---|
| |

Кушымталар CD, DVD-чыганак, электрон һәм басма төрдә (видеоматериаллар фотосурәтләр, басма продукция һ.б.) бирелә.

Җитәкченең Ф.И.А.и. _________________________________/_______________________/
(имза)
М.У.

Татарстан Республикасы
Мәдәният
министрлыгының
04.08.14 елның 880од
_____номерлы
боерыгына 2 нче
кушымта

**Россия Федерациясе төбәкләренең 2014 елда этномәдәни проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы иҗтимагый оешмаларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы грантларын алучыларны билгеләү советы составы**

| | |
|---|---|
| Сибагатуллин<br>Айрат Миңнемулла улы | Татарстан Республикасы мәдәният министры, Совет рәисе |
| Гыйльметдинов<br>Илдар Ирек улы | Совет рәисе урынбасары,<br>Татарларның федераль милли-мәдәни мохтарияте советы рәисе (килешү буенча) |
| Закиров<br>Ринат Зиннур улы | Совет рәисе урынбасары,<br>Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе (килешү буенча) |
| **Совет әгъзалары:** | |
| Нигъмәтуллина<br>Гүзәл Азат кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары |
| Әхмәтҗанова<br>Лилия Марс кызы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының милли мәгариф идарәсе башлыгы |
| Айтуганова<br>Миләүшә Ләбиб кызы | «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» ААҖ генераль директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Бәдретдинова<br>Алина Хәмзә кызы | Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты Милли сәясәтне гамәлгә ашыру идарәсе баш киңәшчесе |
| Вәлиев<br>Рафаэль Миргасыйм улы | «Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты» федераль дәүләт бюджет |

| | |
|---|---|
| | югары һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе проректоры, тарих фәннәре докторы, профессор (килешү буенча) |
| Габдрахманова Гөлнара Фоат кызы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге институты Этносоциология тикшеренүләре үзәге җитәкчесе, социология фәннәре докторы (килешү буенча) |
| Җәүһәрова Фәнзилә Хәким кызы | «Традицион мәдәниятне үстерү республика үзәге» ДБУ җитәкчесе |
| Миңнуллин Ким Мөгаллим улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры (килешү буенча) |
| Таишев Марсель Мазһар улы | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет рәисе (килешү буенча) |
| Төхвәтуллин Рәис Гыйният улы | Татарстан Республикасы Язучылар берлеге рәисенең гомуми мәсьәләләр буенча урынбасары (килешү буенча) |

Россия Федерациясе төбәкләренең 2014 елда этномәдәни проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы иҗтимагый оешмаларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы грантларын алуга конкурс турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

# КИЛЕШҮ

**Казан шәһәре** **«___»__________2014 ел**

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, алга таба Министрлык дип аталып, Татарстан Республикасы мәдәният министры А.М.Сибагатуллин йөзендә, бер яктан, һәм __________________________________________________________, икенче яктан, алга таба – Оешма, түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

## 1. Килешү предметы

1.1. Әлеге Килешүдә ______________________________________________ номинациясендәге этномәдәни проектны гамәлгә ашыру өчен грант-субсидия бирүнең тәртибе һәм шартлары билгеләнә.

## 2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Министрлык _____________________күләмендә ___________________ грант-субсидия күчерергә бурычлы була.

2.2. Министрлык түбәндәгеләргә хокуклы:

Оешмадан әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәү, шулай ук әлеге Килешүдә каралган тикшерүләрне (контрольлек чараларын) уздыру өчен кирәкле мәгълүматны, документларны соратып алырга;

әлеге Килешү кысаларында Оешманың үзенә алган бурычларын үтәвен контрольдә тоту;

әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган акчаның тиешле максатларда һәм нәтиҗәле файдаланылуын контрольдә тоту;

Оешма тарафыннан әлеге Килешүнең үтәлүе белән бәйле тикшерүләр һәм башка контроль чаралары уздыру.

2.3. Оешма үз өстенә түбәндәге йөкләмәләрне ала:

әлеге Килешүнең 2.1 пунктында күрсәтелгән гарнт-субсидиянең тиешле максатларда файдаланылуын тәэмин итү;

Министрлык соратуы буенча, шулай ук башка вәкаләтле органнарга алар билгеләгән срокларда Оешма тарафыннан әлеге Килешүнең үтәлүе белән бәйле тикшерүләр һәм башка

контроль чаралары уздыру өчен кирәкле мәгълүматларны һәм документларны тапшыру, шулай ук Министрлыкка мондый тикшерүләр (контроль чаралар) уздыруда ярдәм итү;

Килешү кысаларында чараларны уздыру барышы турында Министрлыкка мәгълүмат тапшыру;

Министрлыкка грант–субсидияләр түләүгә бүлеп бирелгән акчаны тиешле максатларга тоту белән бәйле чыгымнарны гамәлгә ашыру турындагы хисапны беренчел бухгалтерлык документларын теркәп (шартнамә, акт, контракт, счет-фактуралар) тапшыру.

2.4. Оешма түбәндәгеләргә хокуклы:

әлеге Килешү буенча йөкләмәләрен үтәү белән бәйле мәсьәләләр буенча кирәкле консультацияләр һәм аңлатмалар алырга;

Оешма тарафыннан әлеге Килешүнең үтәлүе белән бәйле тикшерүләр һәм башка контроль чаралары уздыруда катнашырга.

## 3. Грант – субсидияләр буенча бүлеп бирелгән акчаны тиешле максатларга тоту турында хисап

3.1. Грант-субсидияләр алучылар 2014 елның 19 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына грант-субсидияләр түләүгә бүлеп бирелгән акчаның тиешле максатта файдаланылуы һәм иҗади эшчәнлек нәтиҗәләре турында хисап бирәләр.

3.2. Грант-субсидияләр түләүгә бүлеп бирелгән акчаның тиешле максатка файдаланылуы турында хисап ике нөсхәдә язмача бирелә.

## 4. Грант (субсидия) күчерүне вакытлыча яисә бөтенләй туктату өчен нигезләр

4.1. Грант (субсидия) күчерүне вакытлыча яисә бөтенләй туктату түбәндәге очракларда башкарыла:

грант-субсидияләр бирү шартларын үтәмәү;

грант-субсидияләрне тиешле максатка файдаланылмавы;

Оешма тарафыннан әлеге Килешүдә билгеләнгән формаларда, тәртиптә һәм срокларда хисап бирелмәү.

Әлеге Килешүнең 4.1 пунктында күрсәтелгән сәбәпләр килеп чыкканнан соң 10 (ун) эш көне дәвамында Министрлык Оешмага акча күчерүнең аның сәбәпләре бетерелгәнче туктатылып торуы турында вәкаләтле вазыйфаи зат кул куйган хәбәрнамә җибәрә.

Хәбәрнамәдә субсидия күчерүнең туктатылып торуы сәбәпләрен, шулай ук Оешма тарафыннан субсидия күчерүне туктатып торуга нигез булган сәбәпләрнең бетерелүен раслаучы документлар тапшыру өчен ун эш көненнән дә артмаган срокны күрсәтү мәҗбүри.

4.2. Килешүнең 4.1 пунктында күрсәтелгән таләпләрне бозу очракларын бетерүне раслаучы документлар бирелмәгәндә, Министрлык ун көн эчендә Оешмага грант-субсидия күчерүнең туктатылуы турында хәбәрнамә җибәрә.

## 5. Килешүнең гамәле вакыты һәм аны үзгәртү яисә өзү тәртибе

Әлеге Килешү аңа Яклар тарафыннан кул куелган көннән үз көченә керә һәм әлеге Килешү буенча Яклар тарафыннан үз йөкләмәләрен үтәгәнгә кадәр гамәлдә була.

## 6. Бәхәсләрне карау тәртибе

6.1. Әлеге Килешүне үтәү барышында Яклар арасында туган бәхәсләр (каршылыклар) алар тарафыннан тиешле беркетмәләр һәм башка документлар рәсмиләштерү, сөйләшүләр уздыру юлы белән мөмкин булганча хәл ителә.

6.2. Бәхәсләрне хәл итү мөмкин булмаган очракта, бәхәсләр (каршылыклар) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш.

## 7. Форс-мажор

Яклар, йөкләмәләрен тиешенчә үтәү тыелгысыз көч, ягъни гадәттән тыш һәм котылгысыз шартларда (форс-мажор), әгәр бу шартлар йөкләмәләр үтәлмәүгә турыдан-туры сәбәп булса, мөмкин булмавын дәлилли алсалар, йөкләмәләрен үтәмәүләре яисә тиешенчә үтәмәүләре өчен җаваплылыктан азат ителәләр.

## 8. Йомгаклау нигезләмәләре

Әлеге Килешү һәр ике Як өчен берәр, бердәй юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә төзелде.

## Якларның реквизитлары:

| | |
|---|---|
| **Татарстан Республикасы**<br>**Мәдәният министрлыгы**<br><br>420015, Татарстан Республикасы,<br>Казан шәһәре, Пушкин ур. 66/33,<br>Тел.: (843) 264-74-01,<br>факс 292-07-26<br>E-mail: mkrt@tatar.ru<br><br>ИНН/КПП 1654022036/165501001<br>ОКПО 00999754, ОГРН 1021602850884<br><br>**Татарстан Республикасы**<br>**Мәдәният министры**<br><br>**_____________ А.М.Сибагатуллин** | Оешма<br>(Уставтагы атамасы)<br>л/с<br>к/с<br>р/с<br>БИК<br>Банк исеме<br>г.<br>ИНН _______________<br>КПП _______________<br>ОКПО _______________<br>ОГРН _______________<br>ОКТМО_____________ |